# КАРАР

№1

24.11.2025 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге составына керүче Иске Тимошкино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2025 елның 20 мартындагы 33 номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге авыл җирлеге Советы ««Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»05.11.2019 ел №99 карары нигезендә түбәндәге сорау буенча 2025 ел 24 ноябрендә узган җыен нәтиҗәләре беркетмәсе тәзелде :

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

**2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру,җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидлар файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу - ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

**3.Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү**

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы);

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫМ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 523 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 261 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
- «Риза»- 261 катнашучы тавыш бирде;
- «Каршы» -0 катнашучы тавыш бирде;
- «Тыелдым» 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны кабул дип танырга: «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

**2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру,җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидлар файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу - ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

**3.Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү**

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы);

3. Әлеге карарны Иске Тимошкино авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районын рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы Н.М.Сандимиров